| | |
|---|---|
| РУКОВОДИТЕЛЬ<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО<br>КОМИТЕТА<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ<br>ҖИТӘКЧЕСЕ |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ<br>18.09.2017г. | КАРАР<br>№ 13 |

Җирле референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст., 20 ст. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 1 п., «Югары Ослан авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан авыл җирлеге территориясендә түбәндәге мәсьәләләр буенча җирле референдум уздыруның уртак инициативасын чыгарырга:

«2018 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә алынган акчаларны юллау белән килешәсезме:

- Югары Ослан авыл җирлеге территориясендә урнашкан зиратларны төзекләндерү

ӘЙЕ ЮК".

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районының
Югары Ослан авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Д. В. Котков